**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ**
**(IV чакырылыш)**

**КАРАР**
IV чакырылыш IV утырыш

2021 елның 26 феврале №38 Урыссу ш.т.п.

2020 елга Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районының
социаль-икътисадый үсеше йомгаклары һәм
2021 елга бурычлар хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Экологик экспертиза турында» 1995 елның 23 декабрендәге 174-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Советының 2016 елның 28 апрелендәге 18 номерлы карары белән кабул ителгән «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы башлыгы А. Ә. Шәфигуллинның «2020 елга Ютазы муниципаль районының социаль-икътисадый үсеше йомгаклары һәм 2021 елга бурычлар турында» докладын тыңлап һәм фикер алышып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Советы карар кабул итә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы башлыгы А.Ә. Шәфигуллинның «2020 елда Ютазы муниципаль районының социаль-икътисадый үсеше йомгаклары һәм 2021 елга бурычлар турында» докладын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетына 2021 елның 15 мартына кадәр Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башлыгы докладында, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы депутатлары чыгышларында әйтелгән кисәтүләрне һәм тәкъдимнәрне гамәлгә ашыру буенча чаралар планын эшләргә һәм аны Татарстан Республикасы Ютазы район Советына карауга тапшырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында “Рәсми Татарстан” дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм порталы составында “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы район Советының даими комиссияләренә йөкләргә.

Татарстан Республикасы Ютазы
муниципаль районы Башлыгы -
Татарстан Республикасы Ютазы
район Советы Рәисе А. Ә. Шәфигуллин